КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 13 декабрь г.Казань № 1610

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 30 март, 245 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлеген раслау турында» 2022 ел, 12 гыйнвар, 7 нче карары белән расланган «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары исемлегенең 17 пункты;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2019 ел, 30 март, 245 нче карары белән расланган Төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында" 2023 ел, 14 март, 241 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин